МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.03.2023 Казан шәһәре 57

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Министрлыкта Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга бәйле мәсьәләләр тиешенчә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе тарафыннан карала.»;

7 пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләре белән алмаштырырга.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**